СОВЕТ НИЖНЕОШМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д.37А, с.Нижняя Ошма, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422164

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТҮБӘН УШМЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Совет ур., 37А нче йорт, Түбән Ушмы авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422164

тел.(факс): (85563) 2-34-46; e-mail: Noshm.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение — Карар

29 апрель2019 ел — № 1-39

“Түбән Ушмы авыл җирлеге Советының2018
елның 11 апрелендәге 1-30 санлы карары
белән расланган “Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушмы авыл
җирлеге”муниципаль берәмлегетерриториясен
төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм
өстәмәләр кертү турында”Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушмы
авыл җирлеге Советы карары проекты турында

“Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы 2003 ел, 06 октябрь, 131 - ФЗ санлы Федераль закон, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы законы нигезендә, “Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушмы авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Мамадыш районы прокуратурасының 2019 елның 26 февралендәге тәкъдимнәре ,нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципальрайоны Түбән Ушмы авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Түбән Ушмы авыл җирлеге Советының 2018 елның 11 апрелендәге 1-30 санлыкарары белән расланган “Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушмы авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясентөзекләндерү кагыйдәләренә (17.09.2018 ел, 2-34 нче санлы редакциядә) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1.Кагыйдәләрнең 2 бүлегенең 13 бүлеген түбәндәге эчтәлекле 56 пункт белән тулыландырырга:

“ 56. Юридик затлар (шәхси эшмәкәрләр) һәм физик затлар Сосновский балтырганының таралу чыганакларын ачыклау, үзләренең милкендә биләүдә яки куллануда булган җир участокларындаСосновский балтырганынбетерү (юк итү), аннан арындыру, бетерү (юк итү) буенча мөстәкыйль рәвештә үз хисабына системалы чаралар үткәрергә тиеш, (Сосновский балтырганын бетерү (юк итү)

буенча чаралар аларбөреләнгәнче һәм чәчәк ата башлаганга кадәр үткәрелергә тиеш)”.

1.2. Кагыйдәләрнең 3 бүлегендәге 26 нчы бүлекнең 171 пунктын түбәндәге эчтәлекле 8 пунктча белән тулыландырырга:

“Сосновский балтырганының таралу чыганакларын ачыклау, үз милекләрендә булган җир кишәрлекләрендәбетерү (юк итү), буенча чаралар юридик затларның (шәхси эшмәкәрләрнең) һәм физик затларның үз акчалары хисабына мөстәкыйль рәвештә Сосновский балтырганыбөреленгәнче һәм чәчәк ата башлаганчы үткәрелергә тиеш.”

2. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушмы авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында, Мамадыш муниципаль районы рәсми сайтында, “Интернет” мәгълүмати- коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр Порталында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушмы авыл җирлеге башлыгына Ганиев Р.М. га йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Түбән Ушмы авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе /Р.М. Ганиев /